КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 декабрь г.Казань № 1349

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 26 сентябрь, 1036 нчы карары белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 26 сентябрь, 1036 нчы карары белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит

булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Субсидия бирү нәтиҗәсе - төзекләндерү эшләрен башкару:

2022 елның 31 декабренә торышы буенча 2022 елда Татарстан Республикасының 40 муниципаль берәмлегендә 1 212 ишегалды территориясе;

2023 елның 31 декабренә торышы буенча 2023 елда Татарстан Республикасының 34 муниципаль берәмлегендә 950 ишегалды территориясе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин